ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.06. 2016 г.Мензелинск № 628

**«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 12 декабрендәге 1241 номерлы карары белән расланган 2015-2020 елларга Минзәлә муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»**

Россия Федерациясе Президентының «2016 - 2017 елларга коррупциягә каршы көрәш милли планы турында» 2016 елның 1 апрелендәге 147 номерлы Указының 10 пункты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 - 2020 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 26 маендагы 354 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 - 2020 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы көрәш сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карары белән расланган «2015 - 2020 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы көрәш сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 26 маендагы 354 номерлы карары нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 12 декабрендәге 1241 номерлы карары белән расланган «2015-2020 елларга Минзәлә муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Программаның 1 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Программа дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар тарафыннан башкарыла торган, Минзәлә муниципаль районында коррупцияне кисәтү, коррупцион хокук бозуларны минимальләштерү эшендә конкрет нәтиҗәләргә ирешүгә юнәлдерелгән хокукый, мәгариф, тәрбия, оештыру һәм башка чараларны килештереп куллануны тәэмин итә торган комплекслы чаралар системасыннан гыйбарәт.";

-Программаның II бүлегенең егерме икенче абзацын төшереп калдырырга;

- Минзәлә районында коррупциягә каршы көрәш буенча район башлыгы каршында” сүзләрен “Минзәлә муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш эшен координацияләү буенча” сүзләренә алмаштырырга

-Программаның IV бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Минзәлә муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш эшен координацияләү комиссиясе һәр квартал саен Программаның аерым чараларын үтәү мәсьәләләре буенча программада төзүчеләр тарафыннан киңәшмәләр үткәрә.";

-Программага кушымтада:

1.2.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Минзәлә районы Башкарма комитеты эшләре идарәчесенә йөкләргә.

Җитәкче И.Т.Шагалиев

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1.2.2. Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт турындагы законнарда каралган чикләүләр һәм тыюларның үтәлешен тикшерү үткәрү, шул исәптән эшкуарлык эшчәнлегендә катнашу предметына «Юридик затларның бердәм дәүләт реестры» һәм «Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестры» Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең мәгълүмат базаларыннан сис файдалану (елына кимендә бер мәртәбә)» | Кадрлар эшен алып бару өчен җаваплы вазыйфаи затлар, район прокуратурасы (килешү буенча) | 2015-2020 еллар | | | | | | | | | | | | | |

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1.3. Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының коррупциягә каршы көрәш бүлекләрен, муниципаль районда коррупциягә каршы көрәш эшчәнлеген координацияләү комиссияләренең, шул исәптән алар эшчәнлегенә җәмәгать советларын һәм граждан җәмгыятенең башка институтларын җәлеп итү юлы белән, эшчәнлекләренең ачыклыгын тәэмин итү» | Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча район башлыгы ярдәмчесе - комиссия секретаре Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы комиссиясе, мәгариф бүлеге, мәдәният бүлеге, ОДМС | 2015-2020 еллар | | | | | | | | | | | | | |

түбәндәге эчтәлекле 1.3.1 пункт белән тулыландырырга:

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1.3.1 Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының коррупциягә каршы | Татарстан Республикасы | 2016-2020 | тиешле комиссияләрнең | | | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| көрәш бүлекләре, муниципаль районда коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссияләре җитәкчеләре каршындагы комиссияләр эшенең еллык планнарын раслауны һәм киләчәктә үтәүне тәэмин итү» | Минзәлә муниципаль районының мәгариф бүлеге, мәдәният бүлеге, ОДМС | еллар | уздырылган утырышлары саны елга | | | | | | | | | | | | |

4.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «4.6. Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан чикләүләрне, тыюларны үтәү, шулай ук вазыйфаларны башкару буенча оештыру, аңлату һәм башка чаралар комплексын гамәлгә ашыру,<br>коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән, шул исәптән бүләкләр бирүгә һәм алуга кагылышлы чикләүләр, бу эшкә Минзәлә муниципаль районы иҗтимагый советларын һәм коррупциягә каршы көрәштә катнашучы иҗтимагый берләшмәләрне һәм граждан җәмгыятенең башка институтларын җәлеп итеп | Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе Кадрлар эшен алып бару өчен җаваплы вазыйфаи затлар | 2015-2020 еллар | | | | | | | | | | | | | |

5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «5.7. Массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырылган һәм гражданнардан һәм юридик затлардан килгән мөрәҗәгатьләрдә булган вазыйфаи затлар эшчәнлегендә коррупция чагылышлары турында мәгълүматка мониторинг үткәрү эшен һәр кварталда гомумиләштереп һәм аның нәтиҗәләрен Минзәлә муниципаль районы башкарма комитетының коррупциягә каршы көрәш бүлекләре, муниципаль районда коррупциягә каршы көрәш эшен | Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының мәгариф бүлеге, мәдәният бүлеге, ОДМС<br>Район Советы һәм башкарма комитетының | 2015-2020 еллар | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| координацияләү комиссияләре җитәкчеләре каршындагы комиссияләр утырышларында карап тикшерә» | гомуми бүлекләре Комиссия | | | | | | | | | | | | | | |

8.1 пунктны түбәндәге редакциядәбәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «8.1. Гражданнар муниципаль хезмәт вазыйфасына кергәндә барлыкка килә торган коррупция куркынычларын бетерү максатында муниципаль хезмәт өлкәсендәге законнар таләпләренең үтәлешен тәэмин итү» | Кадрлар эшен алып бару өчен җаваплы вазыйфаи затлар | 2015-2020 еллар | | | | | | | | | | | | | |

түбәндәге эчтәлекле 8.5 - 8.8 пунктлар өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «8.5 Коррупция күренешләрен кыскарту һәм су һәм урман законнарын бозуларны кисәтү өчен чаралар күрү;<br>халыкны урманнардан һәм су саклау зоналарыннан законсыз файдалануга бәйле хокук бозуларны ачыклау максатларында «Халык инвентаризациясе» акцияләрен үткәрү | Комиссия, кишәрлек урманчылыкларының вазыйфаи затлары | 2016-2017 еллар | уздырылган акцияләр саны | | | 1 | 1 | | | | | | | | |
| «8.6 Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәмәгән һәр очракта законнарда каралган юридик җаваплылык чараларын куллануны тикшереп торуны гамәлгә ашыру | Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе Кадрлар эшен алып бару өчен җаваплы вазыйфаи затлар | 2016-2020 еллар | | | | | | | | | | | | | |
| «8.7 Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары алдына куелган бурычларны үтәү өчен төзелгән оешмаларга коррупцияне кисәтү буенча оештыру, | Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча район башлыгы ярдәмчесе - | 2016-2020 еллар | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| аңлату һәм башка чаралар комплексын гамәлгә ашыру» | комиссия секретаре | | | | | | | | | | | | | | |
| "8.8 Муниципаль хезмәттә мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу турындагы законнар таләпләрен үтәүне тәэмин итү" | Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе Кадрлар эшен алып бару өчен җаваплы вазыйфаи затлар | 2016-2020 еллар | | | | | | | | | | | | | |

Башкарма комитет эшләре белән идарә итүче: Т.М.Урошникова